# IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ II СЕССИЯСЕ

## К А Р А Р №12

Мөслим «13» ноябрь 2020 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибе турында**

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Кушымта итеп бирелгән «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару Тәртибен расларга.
2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына 2020 елның 1 декабренә кадәр әлеге карар нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген төзергә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында http://muslumovo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка игълан итәргә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Советының 2020 елның
«13» ноябрендәге 12 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару Тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару кагыйдәләрен билгели.

2. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана. Контроль төрләре исемлеге муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләр нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге тарафыннан төзелә һәм алып барыла.

1) Контроль төрләре исемлеге үз эченә түбәндәге мәгълүматны ала:

2) муниципаль контроль төренең исеме;

3) Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны регламентлаштыручы, шул исәптән муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында норматив хокукый актлар реквизитлары;

3 Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы исеме.

3. Контроль төрләре исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертелә:

1) муниципаль контрольнең яңа төрен кертергә яисә муниципаль контроль төрен төшереп калдыру кирәк булган очракта;

2) муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны регламентлаштыра торган норматив хокукый актларның реквизитларын төгәлләштерү максатларында;

3) муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы исеме үзгәрүгә бәйле рәвештә.

4) Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны регламентлаучы һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләргә үзгәрешләр кертүче норматив хокукый акт үз көченә кергән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча контроль төрләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимне Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрә. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы юкка чыгарылган очракта, контроль төрләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдим юкка чыгарыла торган җирле үзидарә органы вәкаләтләре йөкләнгән җирле үзидарә органына җибәрелә.

5. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты Контроль төрләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимне карый һәм әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдим кергән

көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча, контроль төрләре исемлегенә үзгәрешләр кертә.

6. Контроль төрләре исемлегенә кертелгән мәгълүмат һәркем өчен ачык. Контроль төрләре исемлеге Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.